**СОВЕТ ДЕРЖАВИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422620,Татарстан, с. Державино,
ул. Заббарова, д.39
тел: 3-45-20

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕРЖАВИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422620 Державино авылы,
Заббаров урамы, 39 нчы йорт,
тел: 3-45-20

---

**№ 17** **2019 елның 7 октябреннән**

# РЕШЕНИЕ

# КАРАР

## "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар һәм «муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 21.07.2005 ел, №97-ФЗ Федераль законнар, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Законы нигезендә Державино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Камская новь» («Кама ягы») район газетасында, махсус мәгълүмат стендларында һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (игълан итәргә): http://pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны план-бюджет комиссиясенә һәм икътисадый үсешкә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Державино авыл җирлеге**
**Башлыгы, Совет рәисе**

**Татарстан Республикасы**

**Лаеш муниципаль районы**
**Державино авыл җирлеге**
**Советының 2019 елның 7 октябрендәге**
**17 номерлы карарына Кушымта**

## “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр”

23 статьяның 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «9. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены анда әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыграгы катнашуда вәкаләтле, әлеге Устав нигезендә гражданнар җыены Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авылында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт эчендә уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый.»